ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

03.09.2021 Казан шәһәре № Пр-491/2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен-дә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 167 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларын актуальләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 167 номерлы боерыгына, 3 пунктында «үземне җаваплы итеп билгелим» сүзләрен «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты

рәисенең беренче урынбасары А.Л.Штромга йөкләргә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 13 июлендәге 167 номерлы боерыгы белән расланган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында мәгълүматлар кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктта «кадрлар бүлегенең» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «кадрлар бүлеге» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «кадрлар бүлегендә» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегендә» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктта «кадрлар бүлегендә» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегендә» сүзләренә алмаштырырга.

3. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәисе А.С. Груничев